**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 апрель № 248

г. Казань

Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фондына Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен бирү турында

«Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 ел, 31 декабрь, ФЗ-488 нче Федераль закон, «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 ел, 21 апрель, ТРЗ-24 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды»н (алга таба – Фонд) Татарстан Республикасының сәнәгатьне үстерү фонды итеп билгеләргә һәм аңарга Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме һәм башка ярдәм күрсәтү юлы белән Татарстан Республикасының сәнәгать сәясәте тормышка ашыру өлкәсендә вәкаләтләр бирергә.

2. Фонд сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтүне Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән, шулай ук Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар исәбеннән гамәлгә ашыра, дип билгеләргә.

3. Фондка:

биш көн эчендә Фонд уставына, аны яңа редакциядә бәян итеп, тиешле үзгәрешләр әзерләргә;

түбәндәгеләрне эшләргә һәм расларга:

проектларны сайлап алу тәртибе, шул исәптән проектларны финанслар белән тәэмин итүгә заявкаларга экспертиза тәртибе;

проектларны финанслар белән тәэмин итү шартлары;

проектларны финанслар белән тәэмин итү чарасы буларак бирелгән заемнарны кире кайтаруны тәэмин итү тәртибе;

Фонд тарафыннан бирелгән акчаны кире кайтаруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

проектларны финанслар белән тәэмин итү чарасы буларак бирелгән акчадан аларны кайтарганнан соң файдалану тәртибе.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\248.docx